**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

30.11.2022 | Ульянково ав. | № 11

Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында» 2022 елның 10 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында» 2022 елның 10 октябрендәге 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Финанс-бюджет палатасы» сүзләре алдыннан «тәкъдим итәргә» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның 10 пунктчасында «консолидацияләнгән» сүзен төшереп калдырырга;

3 пунктның 2 һәм 3 пунктчаларында пункта «бюджет акчалары» сүзләреннән соң «Ульянково авыл җирлеге» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә https://ulyan-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче | Ф.А.Сундурова